СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №140 (7313) | 23 ноябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## Хезмәт хакы бәяләрне куып җитәрме?

Бүген сүз гел шул бәяләр тирәсендә чуала. Ирекле бәяләр булачак дигән сүзләр дә еш ишетелә. Табигый ки, болар хәзер беркемне дә шаккаттырмый. Шулай да Россия Президентының указы бераз күңелне җылыта. Шуларның берсе — 1991 елның 1 декабреннән сәламәтлек саклау, мәгариф, культура, фән, суд, хокук сагында торучылар, идарә органнары һәм бюджет финанславында торучы башка оешма һәм учреждениеләр хезмәтчәннәренең хәрәкәттәге тариф ставкасы һәм хезмәт хакы 90 процентка үсәчәге.

Президентның икенче бер указы 1 декабрьдән хезмәт хакын чикләүләрнең бетерелүе хакында. Бу документ предприятие һәм оешмаларга эшләнгән средствоның теләсә күпмесен эшләүчеләр ихтыяҗына тотуда ирекле хокукы бирә.

Боларга сөенергә генә иде дә, тик базар безнең алга куйганча, хезмәт хакы бәяләрне куып җитәрме? — дигән сорау туа.

Президент указлары РСФСРда хезмәткә түләүнең минималь күләмен кертү турында хөкүмәт карарына өстәмә ясый.





## Алар фермада эшлиләр

«Игенче» колхозында урта мәктәпне тәмамлаган яшь кызлар авылда калмаска тырышалар. Моны алар авыр хезмәт шартлары, күңел ачу өчен мөмкинлекләрнең булмавы белән аңлаталар. Ә менә Рәзинә Сәлахова белән Гөлзидә Садретдинова алай фикер йөртмиләр. Бәхетләрен фермада сынап карарга булдылар. Һәм ялгышмадылар да төсле. Икесенә бергә группа җыйдылар, хәзер аларның 45 танасы бар. Фермада эш ике сменада оештырылган. Төшке ялга хәтле савучыларның берсе, ә кичен икенчесе бара. Төш вакытында исә бергәләп килләр.

Яшь кызларның биредә хезмәт куюларына инде ике ел. Шул дәвер эчендә алар барлык төр физик авырлыкларны да үз җилкәләрендә татырга өлгерделәр.

Гөлзидә Садретдинова белән Рәзинә Сәлахова ел башыннан үз карамакларындагы һәр сыердан 563—562 центнер сөт саудылар. Дөрес, күрсәткечләре әлегә әллә ни түгел, әмма киләчәктә яшь сыер савучы кызларның сынатмаячакларына шик юк.

Рәсемдә: «Игенче» колхозының яшь савучылары Рәзинә Сәлахова белән Гөлзидә Садретдинова.

## Экономистлар укыды

Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең укыту планында каралганча, шушы көннәрдә район үзәгендә баш экономистлар һәм барлык хуҗалыкларның хезмәткә түләү буенча экономистлары белән укулар үткәрелде. Беренче булып игенчелек буенча баш агроном Петр Егорович ФЕДОРОВ чыгыш ясады. Ул авыл хуҗалыгы культураларын игү технологиясенең үзенчәлекләре белән таныштырды. Аннан соң сүзне авыл хуҗалыгы, азык-төлек идарәсенең начальник урынбасары Александр Алексеевич БЕЛЯКОВ алды. Терлекчелек тармагы буенча ун айда башкарылган эшләргә йомгак ясагач, иптәш Беляков бу өлкәнең уңай һәм тискәре якларына да тукталды.

Биредә шулай ук хуҗалыкара капиталь төзелеш бүлеге начальнигы Минтәсим Харисович МИННЕБАЕВ та чыгыш ясады. Ул капиталь төзелешне финанслау һәм хуҗалык ысулы белән төзү мәсьәләләрен яктыртты.

Авыл хуҗалыгын механикалаштыру бүлеге начальнигы Мансур Вәлиҗанович ЗӘЙНУЛЛИН авыл хуҗалыгы производствосына кертеләчәк яңа техника белән таныштырды.

Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар буенча баш экономисты Минсәлих Минсафович ШӘҺИДУЛЛИН кадрлар мәсьәләсен кузгатты.

Уку икенче көнне дә дәвам итте. Биредә сүзне авыл хуҗалыгы продуктлары сату һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы, Николай Исаевич ФОМИН алды, ул производствоның экономик эффектлылыгын күтәрү төп факторларның берсе буларак авыл хуҗалыгы продукциясе сыйфатын яхшырту юлларын күрсәтте.

Баш юрист Зәки Мәүлетович МӘХМҮТОВ авыл хуҗалыгында хокук мәсьәләләре һәм хуҗалык администрациясе белән арендаторлар арасында төзелгән килешүнең төп закончалык документы булуы турында сөйләде.

Хезмәткә түләү буенча баш экономист Рәмзия Насыйховна САТДАРОВА түләү үзенчәлекләре белән таныштырды һәм 1992 елга производство-финанс планы төзү буенча кыскача инструктаж үткәрде.

Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге зоотехнигы Харис Кыямович ФӘТКУЛЛИН терлекчелек тармагында технология һәм көтүне яңарту мәсьәләләренә тукталды.

Идарәнең баш бухгалтеры Рияз Гарифуллович САФИУЛЛИН авыл хуҗалыгы производствосын акча белән тәэмин итүдәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән таныштырды, шулай ук инструктаж үткәрде.

Соңыннан сүзне район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең план бүлеге начальнигы Рифкать Рәисович ЙОСЫПОВ алды. Ул хуҗалыкларның ун айдагы финанс эшләренә йомгак ясады.

Кыскасы, экономистлар укуы кызыклы һәм оешкан төстә үтте.

## Ишеттегезме әле...

СССР Дәүләт банкы рәисе урынбасары Арнольд Войлуков күптән түгел банк бүлекчәләренә инде тәмам искергән кәгазь акчаларны әйләнешкә кертергә рөхсәт бирде.

Моны кәгазь купюраларның җитмәве, инфляция эшләргә мәҗбүр итте. Илнең күп кенә төбәкләрендә хезмәт хакы бирергә дә акча юк.

x x x

Татарстан ССР Министрлар кабинетында Кыргызстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасында 1992 елда икътисади хезмәттәшлек һәм хуҗалык элемтәләрен үстерү буенча килешүгә кул куелды.

1992 елда ике республика арасында үзара товар алмашу 83 миллион сум тәшкил итәчәк. Кыргызстан республикасы Татарстанга электр җиһазлары, авыл хуҗалыгы машиналары, йон, мамык, тәмәке, ефәк тукымалар һәм башка әйберләр бирәчәк. Татарстан үз чиратында, Кыргызстан республикасына йөк автомобильләре, торбалар, компрессорлар, медицина җиһазлары, мех әйберләре җибәрәчәк.

x x x

Нефть өстендә утырган Татарстанның якын киләчәктә бензинга булган ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндереләчәк. Зәй районында төзеләчәк нефть эшкәртү заводы елына 9 млн. тонна бензин эшләп чыгарачак. Бу бүген исә Татарстан хөкүмәте Япония, Англия, Корея, Италия, Франция, Чехословакия һәм Канада фирмалары катнашында конкурс игълан итте. Быелның 15 декабрендә иң яхшы дип табылган завод проекты сайланып алыначак.

x x x

Ни өчен кибетләрдән шоколад юкка чыкты дип баш ватучыларга Казанның Вахитов район эчке эшләр бүлеге БХСС хезмәткәрләре тагын бер җавап тапты. Бер көнлек тикшерү нәтиҗәсендә генә дә без тәм-том чыгарыр дип өметләнгән «Заря» фабрикасыннан урланган 100 килограмм шоколад һәм 10 кап затлы кәнфит конфискацияләнде. Тикшерүләр ешайганда безнең авызларга да эләгер ул кәнфит дигәннәре.

x x x

Рәсәйнең элеккеге автономияле республикасы Карелия АССР—хәзер Карелия Республикасы дип йөртелә.

x x x

Литва башкаласы Каунаста экологик чиста продуктлар кибете ачылды. Анда лабораториядә җентекләп тикшерелгән яшелчә һәм җиләк-җимеш кенә сатыла. Бәяләр гадәттәгедән 10—20 процентка югарырак.

## Сайлаучылар игътибарына!

РСФСР халык депутаты Е.А. ШӘРИФУЛЛИНА шәхси мәсьәләләр буенча халыкны халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы бинасында 1991 елның 27 ноябрендә көндезге 12 сәгатьтә кабул итә.

Чиратка язылу өчен телефон: 2—14—52.

## Лаеклы яшәр өчен

Сүз дә юк, җиде кат тирен түгеп тапкан акчага көн күрүче, талоннар пачкасын тотып, кибеттән кибеткә йөрүче кешеләр өчен заман көннән-көн авырая бара. Ә бу көннәр Әфган сугышында ярты исәнлеген калдырып кайтучыларга ничек тәэсир итә икән? Ничек булсын, шулай ук... Район хәрби комиссариатының кызыл почмагына җыелган 50ләп әфганлы нәкъ шул хакта озак сөйләшеп утырдылар. Сүз бик кызу атмосферада барды. Проблемалар чиктән ашкан, ә алар исә һаман да иске: торырга фатир юк, тукланырга продукт җитешми, «Ветеран» кибетеннән һәрвакытта да тиешле әйберне сатып алу мөмкинлеге юк. Кыскасы, «...Әфганлыларга иң беренче чиратта...» дигән закон әле һаман да үтәлми.

«Әфганстанга без җибәрмәдек аларны, льготалар булдыру да артык», —диючеләр дә булыр, мөгаен. Шуңа күрә дә егетләр үз-үзләрен, үз мәнфәгатьләрен яклау, һәлак булып калучыларның гаиләләренә ярдәм итү өчен иң элек сугышчы -интернационалистлар клубының эштән азат ителгән рәисе булырга тиеш дигән фикергә килделәр. Хәер, үзгәреш булмаса тәвәккәлрәк адымнар ясау, ягъни соңгы чиккә бару турында да сүз булды биредә.

Нәтиҗәдә Сергей Мингалимовны яңа рәис вазифасын үтәрлек иң кулай кеше итеп таптылар. Һәркайсы эш хакларының бер процентын яңа рәискә җибәреп торырга карар кылдылар. Счет номеры —42842. Ул район үзәк саклык кассасында.

Тик азат ителгән рәис сайлап кына проблемалар чишелерме? Бу сорау әле егетләрнең үзләрен дә борчый калды.

Ф. ГАЛИМОВА.

*Техника ремонтлау бара*

# Игътибар үзәгендә

Киләсе ел уңышы турында кайгырту иң элек авыл хуҗалыгы техникасын язга тиешенчә әзерләүдә чагыла. Хәзер хуҗалыкларда нәкъ шундый мәшәкатьле чак. Көзге чәчү һәм урып-җыю эшләреннән соң барлык бөртек җыю, азык җыю, чөгендер алу комбайннары, механизмнар, чәчкечләр. ургычлар колхозның машина-трактор паркында ачык мәйданчыкларга саклауга куелдылар. Катоклар, культиваторлар, таккычлар һәм тагылма машиналар, җайланмалар да шунда сакланалар. Агрегат һәм машиналардан шланглар, сошниклар, табаннар, каешлар салдырылган, ә резина өлешләре известь-акшар эремәсе белән буялган.

Үзәк ремонт мастерское аерым тотып алынган, биредә салдырылган узел һәм агрегатларны саклау өчен склад, запас частьләр склады, ягулык-майлау материалларын саклау базасы, автомобиль паркы һәм тракторларны ремонтлау өчен бина бар.

Бер сүз белән әйткәндә, авыл хуҗалыгы техникасына сыйфатлы ремонт һәм саклау үткәрү өчен шартлар начар түгел. Колхозның идарә утырышында һәм механизаторлар арасында да ремонтны үткәрү мәсьәләсе каралды. Быел техниканы 1992 елның язгы кыр эшләренә үзвакытында һәм сыйфатлы итеп әзерләү инициативасы белән колхозның өченче бригадасы механизаторлары (бригадирның техника буенча ярдәмчесе Наил Әхмәтҗанов) чыктылар һәм беренчеләрдән булып ремонт эшенә дә керештеләр. Биредә ремонт звеносы төзелде, анда Исхак Вәлиев, Насыйх Хөсәенов, Азат Гинаев, Ибраһим Хөсәенов кебек тәҗрибәле механизаторлар кертелде. Алар үз карамакларындагы техниканы сүтеп, чистарталар, комплектлыйлар, җыялар һәм әзер машинаны сынап та карыйлар. Егетләр үз эшләренә намус белән карыйлар, алар кулы аша үткән техника икенче яшәү ала. Звено бүгенге көнгә 15 данә ЗКК-6, 8 данә ККН-2,8 катогын, С-11 маркалы 12 таккыч һәм ике чәчкечне ремонтлап әзерлек сызыгына куйды инде. Әлбәттә, ремонтның барышы материаль-техник средстволарга,запас часть, ремонт материаллары, узеллар һәм агрегатлар белән тәэмин ителешкә дә бәйле. Бу яктан хәл безнең XXI партсъезд исемендәге колхозда да мактанырлык түгел. Колхоз подшипниклар, металл, запас частьләр һәм узелларны аз ала. Шуңа да күбрәк механизаторларның үзләренә иске узелларны, деталь-частьләрне реставрацияләү белән шөгыльләнергә туры килә. Аларның бер өлешен— иске культиватор табаннарын, чәчкеч сошникларын, шланг һәм эшче цилиндрларны алыштыру, комплектлау өчен ремонттехник предприятиегә тапшырдык һәм аларның яртысын алдык та инде. Тракторларның да бер өлеше анда озатылды, ә калган өлешен үзебездә ремонтлыйбыз. Ремонт, иске частьләрне торгызу-ремонтлау эшләрендә колхозның эретеп ябыштыручылары Вәлимәрдән Нигъмәтуллин, Илшат Ибраһимов, Ринат Шәрәфиев, тимерче Әсгать Сабитов, токарь Илдус Нуретдинов, бакырчы Замир Нуретдиновларның да хезмәт өлеше күп керә.

Тырмаларны ремонтлау буенча бездә икешәр кешедән торган өч группа оештырылды. Өченче бригададан Хәммәтшәриф Вәлиев, Хөҗҗәт Мирзаханов 350 тырманы сафка бастырып, үз йөкләмәләрен үтәделәр инде, ә I—II бригадада Рафик Мифтахов, Александр Секретов, Айдар Хәйруллин һәм Илшат Фасыйхов бу эшне дәвам итәләр әле.Бу бригадаларда техника җылы биналарда механизаторлар көче белән ремонтлана. Габделәхәт Хөснетдинов, Камил Ибраһимов, Рафик Вафин, Рафаэль Дәүләтшин, Равил Фәйзуллин, Сәмигулла Ситдыйков, Җәмил Нуретдинов, Хаҗиәхмәт Мирзаханов, Хөсәен Гатауллин һәм башкалар үз эшләренә бик җаваплы карыйлар. Гомумән, авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау колхозда иң төп эшләрнең берсе итеп игътибар үзәгендә тора. Механизаторлар туфрак эшкәртү һәм чәчү агрегатларын ремонтлауны 1 декабрьгә, тракторлар һәм башка техниканы ремонтлауны 1992 елның 1 апреленә төгәлләүне максат иттеләр.

**Җ. ХӘЙРУЛЛИН,**
XXI партсъезд исемендәге колхоз.

# РСФСР пенсия фондының райондагы эшләре

РСФСРның пенсия фонды. Бу яңа исем агымдагы ел башыннан РСФСРның Югары Советы президиумы карары белән барлыкка килде. Бу яңа структураның түбәнге звеносы булып —районнарның пенсия фонды тора.

Күпләрдә, бу нинди максаттан чыгып эшләнде соң, дигән сорау туарга мөмкин. Аның төп бурычы —яше һәм инвалидлык буенча, туендыручысын югалткан гаиләләргә, социаль, хәрби пенсияләр түләү өчен, сугышта һәлак булганнарның гаиләләренә, ялгыз аналарның балаларына, күп балалы гаиләләргә, 1,5 яшькә кадәр һәм 1,5 яшьтән 6га кадәр һәм инвалид балаларга пособиеләр түләү өчен айлык акча средстволары туплау; милек һәм хуҗалык итү төрлелегенә карамастан, районның барлык предприятиеләренең, оешмаларның һәм аерым гражданнарның страхование взнослары хисабына берәр тапкыр бирелә торган ярдәм күрсәтүен оештыру, взнос күләмен ел саен РСФСРның Югары Советы билгели.

1991 елда предприятие, оешмаларның взносы 20,6 процент тәшкил итте, эшләүче гражданнар аны эш хакының 1 проценты күләмендә түлиләр. Шәхси хезмәт белән шөгыльләнүчеләр һәм шулай ук фермерлар елына 1 тапкыр керемнең 5 проценты күләмендә; договор белән аерым кешеләргә ялланып эшләүчеләр өчен, предприятиеләргә билгеләнгән норма каралган.

Страхование взнослары күчерү эше безнең районда ничек тора соң? РСФСРның пенсия фонды уполномоченныйлары булып Октябрь районы буенча 245 түләүче расланган. 1991 елның 1 ноябренә алардан кергән взнос суммасы 9248553 сум тәшкил итә.

Хәзер исә 36 түләүче—колхоз-совхозларга тупырак тукталасы килә. Алар күчергән взнос күләме бөтен сумманың 1812638 сумын тәшкил итә. Ләкин 7 колхозның 1324009 сумлык күчерелә~е бурычы бар әле. XXI партсъезд исемендәге, «Алга», «Чирмешән», «Восход», М.Җәлил исемендәге, «Чишмә», «Таң» кебек колхозларның 10 ай буе әле бер сум да күчермәүләрен әйтсәк, бу зур сумма бер дә гаҗәпләнү тудырмый.

Бүгенге көндә ПФның акча средствосы пенсия һәм пособиеләр түләү чыгымнарын тулысы белән капларга җитәрлек түгел. Чыгымнар 10 айга 25385271 сум 75 тиен тәшкил итте.

Районда пенсия һәм пособиеләр тулысынча түләнеп барылса да, бу әлегә РСФСР пенсия фонды дотациясе исәбеннән генә мөмкин. Районның 807701 нче пенсия фонды счетыннан җитмәгән средстволар өчен 10 айда гына да 54 мең сум алынды. Бу исә югарыда әйтелгән колхозларның һәм аерым гражданнарның фонд белән тулы хисап ясамаулары нәтиҗәсе. Ә бит взнослар пенсия күләме билгеләнә торган һәр төр хезмәт хакыннан алына. Биредә шулай ук штаттагы, штаттан тыш һәм вакытлы алынган хезмәткәрләр, берьюлы ике урында эшләүче, яки кыска вакытлы эш һәм бер тапкыр гына башкарыла торган эш башкаручылар тарафыннан да билгеләнгән чыгымнары кичерелгән өлешеннән ай саен взносларны күчерү зарурилыгын әйтү кирәк. Райфо хезмәткәрләре белән үткәрелгән 25 тикшерү бу эштә әле кимчелекләр дә җитәрлек булуын ачты: бар җирдә дә страхование взносларын басып калуның төгәл исәбе юк, лицевой счет тотылмый.

Яңа пенсия фондының эшендә, әлбәттә, уңай һәм тискәре яклары бар һәм алар эш барышына да йогынты ясый. Монда бигрәк тә баш бухгалтерларның үз эшләрен намус белән башкарулары сорала. Шулай бергәләшеп кенә эшнең тулысынча һәм үз вакытында башкарылачагына өметләнеп була. Килеп чыккан барлык сораулар буенча 2—15—98 номеры белән шалтыратып белешергә мөмкин.

**В. ХОМЕНКО,**
РСФСР пенсия фондының Октябрь районы буенча өлкән уполномоченные.

# Күршеләребез ничек яши?

**КОШКИ БАЗАРЫНДАГЫ БӘЯЛӘР**
**(Мәгълүматлар —узган якшәмбедән).**

Дуңгыз ите—10—17 сум (1 кг).
Сыер ите—12 сум (1 кг).
Сарык ите—17—18 сум (1 кг).
Тавык түшкәсе—25—40 сум.
Үрдәк түшкәсе—35—40 сум.
Куян түшкәсе—30 сум.
Каз түшкәсе—55 сум.
Сөт—4 сум (3 л).
Каймак—10 сум (1 л).
Ак май—30 сум (1 кг).
Сары май—30 сум (1 кг).
Үсемлек мае — 4 сум (1 кг).
Эремчек—2 сум (1 кг).
Йомырка—5 сум (1 дистә).
Бәрәңге—15 сум (1 чиләк).

Помидор—3 сум (1 кг).
Суган—4—5 сум (1 кг).
Сарымсак—20 сум (1 кг).
Алма—6 сум (1 кг).
Кишер —15 сум (1 чиләк).

Көнбагыш—50 тиен (1 стакан).

Бал—120 сум (3 л).
Маринадланган гөмбә—8—10 сум (1 л).

Маринадланган кыяр—8 сум (3 л).

Бодай 90—110 сум (1ц).

Арпа—80 сум (1 ц).

Катнаш азык—40—50 сум (1 ц).
Витаминлы үлән оны—70 сум (1 ц).
Он—155 сум (1 ц).
Дуңгыз баласы (тере үлчәм)—8 сум (1 кг).
Йон—25 сум (1 кг).
Сарык—100—120 сум (1 баш).
Атлар—үзара килешү буенча.

**ЧАБАКСАР ШӘҺӘРЕНДӘ**

Май—40 сум (1 кг).
Бал—60 сум (1 кг).
Бәрәңге—2 сум (1 кг).
Тозлы кәбестә—5 сум (1 кг).
Тозлы кыяр—8 сум (1 кг).
Суган—4 сум (1 кг).
Кишер—4 сум (1 кг).
Торма—3 сум (1 кг).
Сарымсак—20 сум (1 кг).
Алма—13 сумга кадәр. (1 кг).

**САРАНСК ШӘҺӘРЕНДӘ**

Май—40 сум (1 кг).
Бал—40 сум (1 кг).
Бәрәңге—2 сум (1 кг).
Тозлы кәбестә—4 сум (1 кг).
Тозлы кыяр—6 сум (1 кг).
Суган—4 сум (1 кг).
Кишер—4 сум (1 кг).
Торма—4 сум (1 кг).
Сарымсак—22 сум (1 кг).
Алма—13 сум (1 кг).

**САРАТОВ ШӘҺӘРЕНДӘ**

Май—40 сум (1 кг).
Бал—40 сум (1 кг).
Бәрәңге—3 сум 50 тиен (1 кг).
Тозлы кәбестә—4 сум (1 кг).
Тозлы кыяр—4 сум (1 кг).
Суган— 4 сум (1 кг).
Кишер—5 сум (1 кг).
Торма—3 сум (1 кг).
Сарымсак—20 сум (1 кг).
Алма—12 сум (1 кг).

**ЙОШКАР-ОЛА ШӘҺӘРЕНДӘ**

Май—40 сум (1 кг).
Бал—40 сум (1 кг).
Бәрәңге—1 сум 70 тиен.
Тозлы кәбестә—3 сум 30 тиен (1 кг).
Тозлы кыяр—8 сум (1 кг).
Суган—5 сум (1 кг).
Кишер—1 сум 80 тиен (1 кг).
Торма—2 сум (1 кг).
Сарымсак—30 сум(1 кг).
Алма—11 сум (1 кг).



**Якшәмбе көн базарда. В. Хлебалин фотосы.**

# „КӨЗГЕ БАЛ“

«Эврика» яшүсмерләр клубы күптән түгел «Көзге бал» үткәрде.

—Бездә төрле кичәләр һәр ай саен булып тора, күптән түгел генә «Могҗизалар кыры» оештырган идек,—дип сөйли клубның директоры Валерий Хөсниев.

Соңгы кичәдә клубта түгәрәкләр оештыручылар яшүсмерләр белән бергәлектә төрле кызыклы уеннар хәзерләгәннәр иде. Әйтик, «Призны үзең сайлап ал», «Мисс соклану» һәм башкалар. Биредә йөрүче кызлар, егетләр, иптәшләре бу кичтә бик күңелле ял иттеләр.



## КИЧ УТЫРГАНДА

*Конкурска*

# ТУГАН ЙОРТ

Авылда чакта ничектер ул чаклы игътибар итмәгән идем, бүген менә газетада басылган «туган йорт» фоторәсеменә карап уйга баттым: туган ил дибез, туган җир дибез, туган тел дибез—әбит кеше өчен боларның һәммәсе туган нигез, туган йорттан башлана икән бит.

Иң беренче тапкыр якты дөньяга килгәнлегеңә аваз биреп, түр бүлмәдә эленгән сиртмәле бишектә тирбәлеп, яңа ачылган зәңгәр күзләрең белән әле төсләрне дә ачык аера алмаган килеш, тирәюньгә күз салып ятулар да ата-анаң нигез итеп корган туган йортта башлана икән.

Челтәрле кәрнизле, ачык зәңгәр төскә буялган туган йорт тәрәзәләре! Сезнең аша без тәпи йөри башлаганчы Ук якты,киң, илаһи зур дөнья белән танышканбыз, яңа көн туып, алсу нурларга чумган кояш чыгышына, офыкларда кичке шәфәкъ баешына, энҗе бөртекләрен сирпеп тәңкә-тәңкә апак карлар явуына, көмеш яңгыр тамчыларының коймага бәреп җиргә тамуына—синең аша карап сокланганбыз, синең аша табигатьнең гаҗәеп гүзәл мизгелләре, искитәрлек үзгәрешләре белән танышканбыз. И туган йорт! Синдә без мөстәкыйль,тулы хокуклы, ирекле, хисләренә, уйларына хуҗа булырлык кешеләр булып үстек.

Инде менә сине калдырып, чит җирләрдә каңгырар көннәр җитте. 11 ел буе бергә укып, туганнар кебек дус, тату сыйныфташлар туган нигезләребезне калдырып төрлебез төрле якка таралыштык. Кешеләр дә кошлар кебек, канатлары ныгыгач туган нигезләреннән мөстәкыйль тормышка очарга тиешләр икән. Тормыш законнары никадәр кырыс, ләкин гадел. Табигатьнең һәр баласы үз көнен үзе күрә белергә тиеш. Кая яшәп, кем булуына карамастан, туган йорт, туган нигез һәр кеше күңелендә иң изге, иң кадерле ядкарь булып сакланадыр, мөгаен. Минем өчен дә тәрәзәләре кыйблаларга туры баккан, күңелемә иман нуры иңдереп, җанымны мәрхәмәтле шәфкать орлыклары белән сугарган туган йортым гомерлек таянычым, тормыш юлларында адашмаска юл күрсәтүче олы маягым, кая барсам да сагынудан сары сагышларга уралып, ашкынып кайтыр туган төбәгем, тукталыр төп ноктам булып калыр.

И туган йорт. Нигезеңдә
Ничә буын нәсел-ыру
Җан яраткан
тамырлары
Мөмкинме соң
кибеп кору?!
Кан тартмаса җан
тарта дип
Борынгылар белеп әйткән
Гомер буе сагынырлык
Туган йорт ул—изге
ядкарь.

**Фиалка МӨХӘММӘТОВА,**
КДУның журналистика факультеты студенты.


**«НОРЛАТ СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ФИРМАСЫ**

ТЕЛӘСӘ НИНДИ АЗЫК-ТӨЛЕК, ЧИМАЛ, ТӨРЛЕ МАТЕРИАЛЛАР, ҖИҺАЗЛАР (ЯҢА ҺӘМ ТОТЫЛГАННАРЫ), ХАЛЫК КУЛЛАНУЫ ТОВАРЛАРЫН САТУ, САТЫП АЛУ, АЛМАШТЫРУ СЕЗНЕҢ ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ.

СЕЗНЕҢ ҺӘР ТӨРЛЕ ТӘКЪДИМЕГЕЗ ИСӘПКӘ АЛЫНАЧАК.

«НОРЛАТ СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ФИРМАСЫ—УЛ СЕЗНЕҢ ПРЕДПРИЯТИЕГЕЗНЕҢ УҢЫШЫ ҺӘМ ТАБЫШЫ.

БЕЗНЕҢ АДРЕС: СОВЕТ УРАМЫ, 117.
ТЕЛЕФОННАР: 2—14—69, 2—15—96.


Ш. Гобәйдуллин

## МОҢСУ ТӨНДӘ

Елга буендагы таллар
Әкрен генә сөйләшә
Аларның үз телләре бар,
Шуны тыңлый Миләүшә.

Төнге елга өстендә,
Ай нурлары биешә.
Бик күңелле булыр иде
Ай кызы да биесә.

Шундый моңсу айлы
төндә
Уйлар моңсуланалар.
Уяна күңел төбендә
Онытылган яралар.

Ай кызы белән киңәшә,
Моңаеп калган кызлар.
Алар биргән сорауларга
Җавап бирә йолдызлар.

## *Нәниләр сөйли*

—Энекәшеңнең исеме ничек?—дип сорый кунак апа Ләйләдән.

—Белмим шул, сөйләшә белми бит әле ул.

x x x

Беркөн Илдар велосипедын җимереп өйгә кайтып керә. Аны күреп алган Илнар әтисе янына йөгереп килә дә:

—Эти, Илдар тагын велосипедын ваткан, менә мин кечкенә чакта бер әйбер дә ватмый идем,—шулай бит? —ди юмаланып.

—Ник син ватмый идең соң, улым?—дигән әтисе.

—Минем кечкенә чагымда велосипедым юк иде, оныттыңмыни?—дигән Илнар әтисенең күзенә карап.

**Гаяз ТАҖИЕВ,**
шәһәрнең 4 нче мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.


## Сезгә ничек хезмәт күрсәтәләр?



Теләсә нинди ашханәгә килеп кергәч, беренче күзгә ташланганы—андагы тәртип һәм чисталык була. Әгәр шушы таләп үтәлмәсә, ашаганың аш булмаганы һәммәбезгә мәгълүм.

Киекле ашханәсе коллективына бу яклап сүз тидерерлек түгел. Залда да пөхтәлек хөкем сөрә, ризык салынган савыт-саба, аш-су булә торган өстәлләр дә ялт итеп тора. Ашханәдә бу чисталыкны, тәртипне булдыруда Саимә апа Нуруллинаның өлеше зур. Холкы белән сабыр, күңеле белән аналарча гел яхшыга гына омтылып торучы бу апаның бер генә минут та тик торганын күрмәссең. Үзенең төп вазифаларын үтәп бетерсә, янәшәсендәге кызларга булыша башлый, хезмәттәшләренең эшен җиңеләйтә ул. Арада өлкән кешеләрнең берсе буларак, яшь җилкенчәкнең эч серен тыңларга да, тормыш авырлыклары килеп тугында аларга киңәш сүзе әйтергә дә еш туры килә аңа. Сүз йөртмәүчән, акыллы, сабыр Саимә апаны хезмәттәшләре үз күрәләр. Ә йомыш белән генә кергән кеше ашханәнең чисталыгын, мондагы тәртипне күрсә дә, үзенең мөнәсәбәтен гомуми «Рәхмәт!»—диеп белдерү белән чикләнә, бу пөхтәлекнең нәкъ менә гади һәм тыйнак шушы хатынның тынгысыз хезмәте нәтиҗәсендә тууын уйлап тормый ул.

Таныш булыгыз: Киекле ашханәсендә эшләүче Саимә Галиулла кызы Нуруллина үзенең хезмәт урынында.



Киекле ашханәсе. Н. Азизов фотосы.

## Ана сагышы

**МИҢСЫЛУ ШӘЙХЕТДИНОВА.**
**Югары Норлат авылы.**

Су буеннан атлап кайтып киләм,
Сыңар чиләк суым кулымда.
Балаларым ни хәл икән диеп,
Ике күзем Әлмәт юлында.
Яшь талларга басып кошлар сайрый,
Зәңгәр күктә болыт агыла.
Чит җирләргә бала чыгып китсә,
Өзгәләнеп ана сагына.
Тал буена басып карап торам
Агым суның ничек акканын.
Газиз ана үзе генә белә
Бала өчен ничек янганын.
Тал буена басып карап торам
Сандугачлар моңлы сайраша
Ризыклары читтә булгач, адәм
Чарасызлык белән адаша.
Һәрбер чишмә өскә бәреп чыкмый,
Җир астыннан күпме юл үтә.
Бу дөнья бит мәңгелеккә түгел,
Туган җирдән еракка китмә!




Норлат шәһәрендә яшәүче сөекле әниебез Роза Хөсәен кызы Уразгильдиеваны 65 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз.

Без телибез сиңа зур бәхетләр,
Күтәренке булсын күңелең,
Гөрләп яшә, картаюны белмә,
Гел шатлыклы үтсен гомерең.

**КЫЗЫ, КИЯВЕ, ОНЫКЛАРЫ.**


**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ:** 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
**ТЕЛЕФОННАР:** мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.

Күләме—1 басма табак. Заказ 140. Тираж 3413.